ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

«19» ноября 2021 ел № 1920

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты Резерв фондының бюджет ассигнованиеләреннән файдалану тәртибен раслау турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 81 статьясы нигезендә һәм көтелмәгән чыгымнарны, шул исәптән авария-торгызу эшләрен һәм табигый бәла-казалар һәм башка гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен бетерүгә бәйле башка чараларны үткәрү, шулай ук башка чараларны финанс ягыннан тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Түбәндәгеләрне расларга:

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты Резерв фондының бюджет ассигнованиеләреннән файдалану тәртибен (1 нче кушымта);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты резерв фондыннан акчалар бүлеп бирү турындагы мөрәҗәгатьләрне карау комиссиясе составын (2 нче кушымта);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты Резерв фондыннан бирелгән акчаларның максатчан кулланылышы турында хисап формасын (3 нче кушымта).

2. «Резерв фонды акчаларын тоту тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2013 елның 25 июнендәге 756а номерлы карарны үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Башкарма комитет җитәкчесе Р. Р. Мөхәрәмов

1 нче кушымта
Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
19.11 2021ел, № 1920
карары белән расланды

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты Резерв фондының бюджет ассигнованиеләреннән файдалану
ТӘРТИБЕ

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды Россия Федерациясе Бюджет кодексының 81 статьясы нигезендә, тиешле елга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетында каралмаган чыгымнарны һәм чараларны финанслау өчен төзелә.

1.2. Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты Резерв фондыннан акчалар бүлеп бирү һәм алардан файдалану тәртибен билгели.

2. Резерв фондын төзү тәртибе

2.1. Резерв фонды район бюджеты чыгымнары составында төзелә.

2.2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты Резерв фонды күләме “Чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджеты турында” Арча район Советы карары белән билгеләнә һәм чыгымнарның гомуми күләменең 3 процентыннан арта алмый.

3. Резерв фондының акчаларын тоту юнәлеше

3.1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты Резерв фонды акчалары көтелмәгән чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә җибәрелә, шул исәптән:

- коткару, авария-торгызу эшләрен башкаруга һәм стихияле бәла-казаларны, янгыннарны, башка гадәттән тыш хәлләрне бетерү белән бәйле башка чараларны үткәрүгә һәм аларны кисәтүгә;

- гадәттән тыш хәлләрне булдырмау максатында кичектергесез эшләр башкаруга;

- әлеге торак урынында теркәлгән һәм яшәгән гражданның агымдагы финанс елында табигый бәла-казалар һәм янгын нәтиҗәсендә торак урыннары зыян күргән очракта, гражданнарга (социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары милекчеләренә, яллаучыларга) бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм түләүгә;

- гражданнар оборонасы, табигатьне саклау, җирле әһәмияттәге эпидемиягә каршы чаралар үткәрүгә;

- район бюджетының тиешле бүлеге (бүлекчәсе) буенча каралган акчалар җитмәгән очракта, муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүгә һәм кызыксындыру характерындагы түләүгә.

- ашыгыч кирәк булган дарулар, медицина билгеләнешендәге әйберләр, медицина җиһазлары сатып алуга;

- авыр матди хәлдәге һәм ашыгыч медицина ярдәменә мохтаҗ гражданнарга бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм күрсәтүгә;

- район алдындагы казанышлары өчен гражданнарга бер тапкыр бирелә торган премияләр түләүгә һәм матди ярдәм күрсәтүгә;

- торак-коммуналь хуҗалык, социаль өлкә, транспорт инфраструктурасы, элемтә объектларында гадәттән тыш хәл аркасында зыян күргән кешеләргә кичектергесез авария-торгызу эшләрен башкаруга яки гадәттән тыш хәл барлыкка килүне кисәтү өчен кирәк булган капиталь характердагы эшләрне башкаруга;

- социаль-мәдәни өлкә, физик культура һәм спорт үсешенә ярдәм итүгә;

- табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне, террорчылык һәм экстремистик наркотик чараларны кисәтүгә юнәлдерелгән гомумдәүләт, республика һәм җирле әһәмияттәге проблемалар буенча очрашулар, күргәзмәләр һәм семинарлар үткәрүгә.

4. Резерв фонды акчаларын бүлеп бирү тәртибе

4.1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты Резерв фондыннан әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктында күрсәтелгән көтелмәгән чыгымнарны һәм җирле әһәмияттәге чараларны финанслауга акчалар бүлеп бирү җирле үзидарә органнары, физик яисә юридик затларның Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетына мөрәҗәгате нигезендә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты Резерв фондыннан акчалар бүлеп бирү турындагы мөрәҗәгать белән бергә физик һәм юридик затлар Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетына күрсәтелгән максатларга чыгымнарны (китерелгән зыян турында яки таләп ителә торган акча күләмне нигезли торган белешмәләр, шул исәптән смета-финанс исәп - хисапларын, калькуляция, чыгымнар накладнойларын, счет-фактуралар һәм проект-смета документларын да кертеп) раслый торган документларны тапшыра.

4.2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты 3 (өч) көн эчендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты Резерв фондыннан акча бүлеп бирү турында кергән мөрәҗәгатьләрне һәм чыгымнарның кирәклеген, кичектергесез булуын раслый торган документларны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты резерв фондыннан акча бүлеп бирү турындагы мөрәҗәгатьләрне карау комиссиясенә (алга таба - комиссия) түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрә:

- Резерв фондыннан акча бүлеп бирүнең кирәклеге яисә кирәк булмавы;

- бүленә торган акчаларның күләмен билгеләү.

4.3. Комиссия составы Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы

Башкарма комитеты карары белән раслана.

4.4. Комиссияне Комиссия рәисе җитәкли һәм аның эшен оештыра.

4.5. Комиссия утырышы кимендә өчтән ике составы катнашканда тулы хокукка ия.

4.6. Комиссия утырышы Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетыннан мөрәҗәгатьләр һәм документлар кергән саен уздырыла.

Комиссиянең һәр әгъзасы бер тавышка ия. Комиссия карарлары анда катнашучыларның гомуми саныннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә. Тавышлар тигез булган очракта, Комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора. Комиссия рәисе утырыш беркетмәсенә һәм кабул ителгән карарга имза сала.

Комиссия әгъзасы утырышта катнашмаган очракта, ул карала торган мәсьәләләр буенча язма рәвештә үз фикерен бәян итәргә хокуклы, аның фикере утырышта игълан ителә һәм беркетмәгә кушып бирелә.

Комиссия әгъзасы кабул ителгән карар белән килешмәгәндә, язма рәвештә үзенең аерым фикерен бәян итәргә хокуклы, ул утырыш беркетмәсенә мәҗбүри рәвештә кушып бирелергә тиеш.

4.7. Комиссия карары тәкъдим итү характерында. Комиссия тарафыннан кабул ителгән карар 2 (ике) көн эчендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетына җибәрелә.

4.8. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты Резерв фонды акчалары Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты күрсәтмәсе нигезендә бүлеп бирелә.

4.9. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты Резерв фондыннан акчалар бүлеп бирү турында күрсәтмә Арча муниципаль районы башкарма-боерык органнары һәм оешмалары карамагындагы акчалар җитәрлек булмаганда кабул ителә. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты Резерв фондыннан акча бүлеп бирү турында күрсәтмәдә ассигнованиеләрнең гомуми күләме һәм аларны алучылар һәм үткәрелә торган чаралар буенча бүлү күрсәтелә. Акчалардан Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты күрсәтмәсендә каралмаган максатларда файдалану рөхсәт ителми.

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты Резерв фондыннан бүлеп бирелә торган акчаларның күләме һәм аларны тоту юнәлеше күрсәтелгән акча бүлеп бирү турында күрсәтмә проектларын Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты Комиссия беркетмәсен алганнан соң 3 (өч) эш көне эчендә әзерли.

4.11. Резерв фондыннан акчалар түләүсез һәм кире кайтарылмый торган нигездә бирелә. Резерв фонды акчалары максатчан характерга ия һәм башка максатларда кулланыла алмый.

5. Резерв фонды акчаларын тоту турында хисап

5.1. Резерв фонды акчалары бүлеп бирелә торган җирле үзидарә органнары, физик һәм юридик затлар, Россия Федерациясе законнарында

билгеләнгән тәртиптә акчаларны максатсыз файдалану өчен җавап бирәләр һәм тиешле чаралар үткәрелгәннән соң бер ай эчендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетына, Резерв фондыннан бирелгән акчалардан максатчан файдалануны раслый торган документларны кушып, хисап тапшыралар.

5.2. Бүлеп бирелгән акча үзләштерелмәгән, бирелгән акчаларны максатчан кулланмаган, дөрес булмаган белешмәләр булган документлар тапшырган очракта, акчалар Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

5.3. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты акча бирүне туктату һәм (яки) кире кайтару турындагы карар кабул итә.

5.4. Акчаны кире кайтару Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының язма таләбе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының территориаль бүлегендә ачылган шәхси счетына күчерү юлы белән бәхәссез рәвештә башкарыла.

5.5. Акчаларны ирекле кире кайтарудан баш тартканда, алар Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә түләтелә.

2 нче кушымта
Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
19.11. 2021ел, № 1920
карары белән расланды

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты Резерв фондыннан акчалар бүлеп бирү турында мөрәҗәгатьләрне карау комиссиясе

СОСТАВЫ

Комиссия рәисе:

| | |
|---|---|
| Мөхәрәмов Р.Р. | Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе |

Комиссия рәисе урынбасары:

| | |
|---|---|
| Вафина Э.Ш. | Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары |
| Сәгыйтова Л.Г. | Юридик мәсьәләләр бүлеге башлыгы |
| Фазылов Р.Р. | Арча муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы |
| Галимуллина Г.Х. | Арча муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм финанслар бүлеге башлыгы |
| Шакирова М.Н. | ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Арча районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе (килешү буенча); |
| Сафин Р.Р. | Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының ТР буенча Баш идарәсе Арча һәм Әтнә МР буенча башлыгы (килешү буенча). |

3 нче кушымта
Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
19.11 2021ел, №1920
карары белән расланды

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты Резерв фондыннан бирелгән акчаларны тоту турында
ХИСАП

Алучының исеме
_______________________________________________

Салым түләүченең идентификация номеры (ИНН)

Үлчәү берәмлеге: сум

| Башкарма комитет күрсәтмәсе | | Чыгымнар юнәлешләре | Акча бирелгән (сум) | Асылда финансланган (сум) | Файдаланылмаган акчаларның калган өлеше | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| датасы | номеры | | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |

Башкарма комитет җитәкчесе ________ ____________________
(имза) (тулы имза)

Баш хисапчы ___________ ____________________
(имза) (тулы имза)

"______" _________20__ ел

МУ